| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАЛТАЧ ШӘҺӘР ЖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

| | |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>«25» декабря 2025ел | **КАРАР**<br>№ 8 |

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Сосна авыл җирлеге» һәм «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре белән чиктәш җирдә «Балтач шәһәр тибындагы поселогы » муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач район Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләре турында»2025 елның 17 декабрендәге 28 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Советының 03.06.2020 № 146 карары белән «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чикләрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Балтач шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү турындагы мәсьәләне тикшерүдә гражданнарның хокукларын үтәү максатларында гавами тыңлаулар уздыру турында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Сосновка авыл җирлеге» һәм «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре белән чиктәш җирдә «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча 2026 елның 14 гыйнварына 11.00 сәгатькә Балтач шәһәр җирлеге бинасында түбәндәге адрес буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә: ТР, Балтач муниципаль районы, ш.ш. Балтач шәһ., Ленин ур., 45 йорт (2 кат).

2. Гавами тыңлауларда карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2026 елның 13 гыйнварында түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Балтач муниципаль районы, пгт. Балтач шәһ., Ленин ур., 45 йорт (2 кат), (Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы). Консультацияләр өчен Телефон: 8 (843)68-3-52-15.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматын рәсми порталында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru), «Хезмәт» матбугат-редакция газетасында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (https://baltasi.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендларында:

- Балтач шәһәр җирлеге, Ленин ур., 45 й.,
- Балтач шәһәр җирлеге, Ленин ур., 52 й.,
- Көек авылы., Ибраһимов ур., 20А й.,
- Курмала ав., Советская ур., 41А й.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин

Балтач шәһәр җирлеге башлыгының
№8 25.12.2025елгы карарына
кушымта

КАРТА-СХЕМА

